Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге
Нырсуар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

28 ноябрь, 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлегенең Нырсуар торак пунктында 2025 елның 28 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 63 (алтмыш өч).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 32 (утыз ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 32 (утыз ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә гражданнар җыенының түбәндәге сорау буенча карары: «Сез, 2026 елда Нырсуар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, 5 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Янсуар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Янсуар авыл җирлеге башлыгы В.Н. Таланов